РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

02.08.2024

№ 636-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 маендагы 706-п номерлы карары белән расланган милеккә арендалана торган милек сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 маендагы 706-п номерлы карары белән расланган арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендага ала торган күчемсез мөлкәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

**1.1.** 2.9.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9.2. Мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендалана торган мөлкәткә түләү бер мәртәбә яисә айлык яисә квартал саен бертигез өлешләрдә түләүләр ярдәмендә кичектереп түләнә.»;

**1.2.** 2.9.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9.3. Мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда аны түләүне кичектереп түләү срогы тиешенчә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый акты, Россия Федерациясе субъекты законы, муниципаль хокукый акт белән билгеләнә, ләкин күчемсез мөлкәт өчен биш елдан да кимрәк һәм күчемле мөлкәт өчен өч елдан да кимрәк булмаска тиеш».

**2.** Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә игълан итәргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе М.Р. Ишниязов